КОМИТЕТ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ПО ОХРАНЕ ОБЪЕКТОВ
КУЛЬТУРНОГО НАСЛЕДИЯ

ТАТАРСТАН
РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ МӘДӘНИ
МИРАС ОБЪЕКТЛАРЫН
САКЛАУ КОМИТЕТЫ

**ПРИКАЗ** **БОЕРЫК**

10.09.2024 № 451-П

Казан шәһәре

Татарстан Республикасы мәдәни мирас объектларын саклау комитеты тарафыннан 2023 елның 31 нче октябрендә 716-П номерлы боерык белән расланган Татарстан Республикасы мәдәни мирас объектларын саклау комитеты тарафыннан Татарстан Республикасы бюджетына түләүләр буенча бурычларны түләтүгә өметсез дип тану турында Карар кабул итү тәртибенә үзгәрешләр кертү хакында

Россия Федерациясе Бюджет кодексының $47^2$ статьясы, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2016 нчы елның 6 нчы маенда гамәлгә кергән «Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетларына түләүләр буенча бурычларны түләтүгә өметсез дип тану турында карарлар кабул итү тәртибенә гомуми таләпләр турында»гы 393 нче номерлы карары нигезендә боерам

1. Татарстан Республикасы мәдәни мирас объектларын саклау комитеты тарафыннан 2023 елның 31 нче октябрендәге “Татарстан Республикасы мәдәни мирас объектларын саклау комитеты тарафыннан Татарстан Республикасы бюджетына түләүләр буенча бурычны түләтүгә өметсез дип тану турында Татарстан Республикасы мәдәни мирас объектларын саклау комитеты тарафыннан карар кабул итү хакында”гы 716-П номерлы боерык белән расланган, Татарстан Республикасы мәдәни мирас объектларын саклау комитеты тарафыннан Татарстан Республикасы бюджетына түләүләр буенча Татарстан Республикасы комитеты администрацияли торган бурычны түләтүгә өметсез дип тану турындагы Татарстан Республикасы мәдәни мирас объектларын саклау комитеты тарафыннан карар кабул итү тәртибенең 2 нче пунктына үзгәрешләр кертеп, түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2. Билгеләнгән вакытта бюджетка түләнмәгән түләүләр (бюджетка түләүләр буенча бурыч) түбәндәге очракларда түләнүгә өметсез дип таныла:

1) бюджетка түләүләр түләүче физик затның вафат булуы яисә аның Россия Федерациясе Граждан-процессуаль законнарында билгеләнгән тәртиптә вафат булган дип игълан ителүе;

2) 2002 елның 26 октябрендә гамәлгә кергән «Бөлгенлек (банкротлык) турында"гы 127-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә гражданның, индивидуаль эшкуарның бюджетка булган бурычлар өлешендә банкротлык процедурасы тәмамлануы, бурычын түләүдән күрсәтелгән Федераль закон нигезендә азат ителүе

3) оешманың мөлкәте җитмәү һәм (яисә) аны гамәлгә куючылар (катнашучылар) тарафыннан Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән чикләрдә һәм тәртиптә түләп бетерү мөмкинлекләре булмау сәбәпле, бюджетка булган бурыч өлешендә, әлеге бурычларны түләүче оешма юкка чыгарылганда;

4) җәзага хөкем ителгәннәргә карата штраф яки суд тарафыннан карар кабул итү рәвешендә амнистия яки ярлыкау турында актлар куллану, шуның нигезендә бюджет керемнәре администраторы бюджетка түләүләр буенча бурычны түләтү мөмкинлеген югалта, шул исәптән аны түләтүнең билгеләнгән срогы тәмамлануга бәйле рәвештә;

5) «Башкару эшчәнлеге турында» 2007 нче елның 2 нче октябрендәге 229-ФЗ номерлы Федераль законның 46 нчы статьясының 1 нче өлешенең 3 нче яисә 4 нче пунктында (алга таба - 229-ФЗ номерлы Федераль закон) каралган нигезне үтәтү документын кире кайтарганда, күләме Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән таләпләр күләменнән артмаган бурыч барлыкка килгән көннән алып биш елдан артык вакыт үтсә, суд приставы-башкаручы тарафыннан башкарма документны кире кайтару турында карар чыгарылып, банкротлык турындагы эш кузгатылганда;

6) банкротлык турындагы эштә кулланыла торган процедураларны үткәрүгә суд чыгымнарын каплау өчен җитәрлек акчалар булмау сәбәпле, бурычлыны банкрот дип тану яки банкротлык турындагы эш буенча эшне туктату турында гаризаны суд тарафыннан кире кайтару турында акт кабул ителү;

7) теркәүче орган карары буенча юридик затны юридик затларның бердәй дәүләт реестрыннан төшереп калдыру һәм 229-ФЗ номерлы Федераль законның 46 нчы статьясындагы 1 нче өлешенең 3 нче яисә 4 нче пунктында каралган нигез буенча, башкарма документны түләтүчегә кире кайтаруга бәйле рәвештә, башкару эшен тәмамлау турында суд приставы-башкаручы тарафыннан элек чыгарылган карарның булуы - оешманың мөлкәте җитәрлек булмау һәм Россия Федерациясе законнарында каралган очракларда, аны гамәлгә куючылар (катнашучылар) тарафыннан түләп бетерү мөмкин булмау сәбәпле, бюджетка түләүләр буенча түләнмәгән бурыч өлешендә. Теркәү органының «Юридик затларны һәм индивидуаль эшкуарларны дәүләт теркәвенә алу турында»гы 2001 нче елның 8 нче августындагы 129-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә юридик затны юридик затларның бердәм дәүләт реестрыннан төшереп калдыру турындагы карары гамәлгә яраксыз дип танылган очракта, элек әлеге пункт нигезендә түләтүгә өметсез дип танылган бюджетка түләүләр буенча бурыч бюджет (бухгалтерлык) хисабына кайтарыла».

2. Боерыкның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемә алам.

Рәис И.Н. Гущин